**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№ 4574**
**14.08.2018 ел**

Дәүләт яки муниципаль мөлкәттәге
җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен
һәм шәхси мөлкәттәге җир кишәрлекләрен
яңадан бүлү турында килешү төзү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр
кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2017 елның 3 октябрендәге 5911 нче карары белән расланган дәүләт яки муниципаль мөлкәттәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси мөлкәттәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктта:

- унберенче абзацны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р нчы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турындагы нигезнамәсе белән (алга таба – ҖММИ турындагы нигезнамә)»;

- түбәндәге эчтәлектәге унөченче абзац белән тулыландырырга:

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ санлы Федераль закон белән (алга таба – 218-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.07.2015, №29 (1 бүлек) 4344 маддә)»;

2) 2.1 пунктта «РФ ҖК ның 39.29 маддәсе» сүзләреннән соң «Муниципаль хезмәтләр исемлеге» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 2.6. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

Постановление

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче аларны алырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирүнең тәртибе | Ведомствоара үзара эшчәнлек кысаларында алына торган документлар:<br>1) Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтәсе (гариза бирүче юридик зат булып саналган очракта);<br>2) Күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>3) Аңардан (алардан) җир кишәрлеге (җир кишәрлекләре) хасил була торган күчемсез милек объекты (объектлары) турында (җир кишәрлеге) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>4) Шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРИП) шәхси эшмәкәр турында өземтә (гариза бирүче шәхси эшмәкәр саналган очракта) | РФ ҖК ның 39.29 маддәсе 4 бүлеге, 210-ФЗ санлы Федераль законның 7, 7.1 маддәләре; 218-ФЗ санлы Федераль законның. 62 маддәсе |

4) 2.11 пунктта «Кадастр паспорты бирү өчен түләү таләп ителми» сүзләрен «кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми» сүзләренә алмаштырырга;

5) 3.4.2. пунктының икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

- белгечләр тарафыннан Росреестрга җибәрелгән документлар (мәгълүматлар), өч эш көненнән дә артык түгел;

- башка куючылар буенча –документлар һәм мәгълүмат бирүче орган яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән алып биш көн эчендә, әгәр җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары белән билгеләнмәгән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителмәгән булса.»;

6) 3.5.3 пунктта беренче абзацта «Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проекты» сүзләреннән соң «әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендә» сүзләре белән тулыландырырга;

7) 4 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4.5 пункты белән тулыландырырга:

«4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контроль Башкарма комитетның муниципаль хезмәт

күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы ачык эшчәнлеге, тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге бирү аша гамәлгә ашырыла.»;

8) 5 бүлекнең исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларын һәм эш итүләрен (эш итмәүләрен) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү тәртибе»

9) 5.1. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитетның вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) карата судка кадәр – Башкарма комитетка, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренә карата –күп функцияле үзәк яисә күп функцияле үзәкне гамәлгә куючы булып саналган тиешле дәүләт хакимияте органының (җирле үзидарә органының) ачык-хокукый берәмлегенә шикаять итәргә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын, 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогы бозылу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүнең срогы бозылу;

3) гариза бирүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту өчен нигез федераль законнарда каралмаган һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган булса;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитет, Башкарма комитет вазыйфаи затларының, күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар тарафыннан җибәрелгән ялгышлар һәм хаталарны төзәтүдән баш тартулары яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогы һәм тәртибе бозылу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр аны туктатып тору өчен федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе

норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралган нигезләр булмаса.»;

10) 5.2-5.4 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон рәвештә бирелә.

5.3.Шикаять почта аша, күп функцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен файдаланып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru.), күп функцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, күп функцияле үзәкнең гариза бирүченең документларын кабул итүдән яисә җибәрелгән ялгышлар һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуын шикаять итү яки андый төзәтмәләргә билгеләнгән срок бозылуны шикаять итү очрагында – аны теркәгәннән алып биш эш көне эчендә.»;

11) 5.5.пунктта:

- 1 пунктчада «Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрен» сүзләреннән соң «Күп функцияле үзәк, аның җитәкчесен һәм (яки)хезмәткәрен» сүзләре белән тулыландырырга;

- 3 пунктчаны «,күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрен» сүзләре белән тулыландырырга;

- 4 пунктчаны «,күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрен» сүзләре белән тулыландырырга;

12) 5.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда кабул ителгән карарны, җибәрелгән ялгышлар һәм хаталар төзәтүне бетерү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләр алынган булса, акча средстволарын мәрәҗәгать итүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.»;

13) 5.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.10. Шикаятьне тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерү очрагында кимчелекне бетерү максатында күрелергә тиешле чаралар билгеләнә. Шикаятьләрне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган очракта, әлеге маддәнең 1 бүлеге нигезендә шикаятьләрне карауга вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.»;

14) 5.11 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Гариза бирүчеләр Башкарма комитет, аның вазыйфаи затларының, шулай ук күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларын,

эш итүләрен (эш итмәүләрен) суд тәртибендә Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять итәргә хокуклы.»;

15) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә 4 нче кушымта белән тулыландырырга;

16) әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 5 нче кушымта белән тулыландырырга;

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет<br>
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 14 августындагы
4574 нче карарына
1 нче кушымта

Дәүләт яки муниципаль мөлкәттәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси мөлкәттәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Яр Чаллы
шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
дәүләт мөлкәте чикләнмәгән җирләрне һәм
шәхси мөлкәттәге җир кишәрлеген
яңадан бүлү турында
КИЛЕШҮ

«_____» _____________ 20___ Яр Чаллы шәһәре

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән Устав нигезендә эш итүче Башкарма комитет Җитәкчесе__________________________, алга таба - «1 нче Як», бер яктан, һәм _______________________, алга таба - «2 нче Як», икенче яктан, бергә алга таба - «Яклар», гариза, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ санлы Федераль законның 3.3 маддәсе 2 пункты һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 маддәсе 1 пункты 3 пунктчасы нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешүнең предметы

1.1. Яклар мәйданы ___ (______________________) кв.м., кадастр номеры _________________, җир категориясе: рөхсәт ителгән рәвештә файдаланылучы торак пунктларның «Татарстан Республикасы_____________» адресы буенча урнашкан, _________________________ шәхси мөлкәтендә булган, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрындагы язу белән расланган _________ №_________________ (алга таба – 1 нче санлы җир кишәрлеге), һәм җирнең дәүләт милке булуы чикләнмәгән өлешендә, мәйданы _____

(____________) кв.м., кадастр кварталы ____________, Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан, шуның нәтиҗәсендә җир кишәрлеге хасил булган, мәйданы ___ (________________________) кв.м., кадастр номеры ___________________, җир категориясе: рөхсәт ителгән рәвештә файдаланылучы торак пунктларның «Татарстан Республикасы, МБ                    » адресы буенча урнашкан, ________________, шәхси мөлкәтендә булган, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрындагы язу белән расланган _________ №________________ (алга таба – 2 нче санлы җир кишәрлеге) җир кишәрлеген яңадан бүлү турында килешүгә ирештеләр.

2 номерлы җир кишәрлегенең мәшәкатьле булуы һәм аңа хокуклар чикләнү җир кишәрлеге турында ____________ ________________ кадастр өземтәсе нигезендә билгеләнә, ул әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора (чикләүләр яки мәшәкатьләр булган очракта).

1.2. Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү Башкарма комитетның____________________ № _________боерыгы белән расланган җир кишәрлегенең урнашу схемасы нигезендә гамәлгә ашырыла (җир кишәрлекләрен яңадан бүлү гамәлгә ашырыла торган чикләрдә территорияне межалау проекты булмаган очракта).

1.3. Әлеге Килешү нигезендә 1 нче номерлы җир кишәрлегенең мәйданы _____ (____________) кв.м.га артты, 2 нче Якның мәйданы __________ ( ) кв.м. булган җир кишәрлегенә милек хокукы хасил була.

## 2. Җир кишәрлеге мәйданын арттырган өчен түләү күләме

2.1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җирләр белән, аны яңадан бүлү нәтиҗәсендә, шәхси мөлкәттә булган 1 нче номерлы җир кишәрлегенең мәйданын арттыруга түләү күләме әлеге Килешү нигезендә һәм гамәлдәге законнар нигезендә _________ (______________________________) сумны тәшкил итә (яңадан бүлү нәтиҗәсендә җир кишәрлеге мәйданын арттыруга түләү исәп-хисабы нигезендә).

2.2. Әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеге бәясен түләү 2 нче Як Килешү проектын алганнан соң 30 көн эчендә_________________________________________________исәп-хисап счетына акча кертү юлы белән башкарыла.

## 3. Җир кишәрлегенә милек хокукы барлыкка килү

3.1. 2 нче номерлы җир кишәрлегенә милек хокукы 2 нче Як әлеге җир кишәрлегенә милек хокукын дәүләти теркәгән моменттан барлыкка килә.

3.2. 2 нче Як, җир кишәрлеге бәясен әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгәнчә түләгәннән соң, 2 нче номерлы җир кишәрлегенә милек хокукын дәүләти теркәүне үз хисабына тәэмин итү йөкләмәсен ала.

3.3. Әлеге Килешү 2 нче номерлы җир кишәрлегенә милек хокукын күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм сату-алу килешүләрен һәм мөлкәткә хокукны туктату, 1 нче номерлы җир кишәрлеген дәүләт теркәвеннән төшерүне гамәлгә ашыручы органда теркәү өчен нигез булып тора.

## 4. Башка шартлар

4.1. Җир кишәрлекләреннән файдалануның әлеге Килешү төзелгәнгә кадәр билгеләнгән чикләүләре һәм мәшәкатьле булуы алар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатылганга кадәр сакланалар.

4.2. Әлеге Килешү белән җайга салынмаган барлык башка мәсьәләләр буенча Яклар гамәлдәге закон нормаларына таянып эш итәләр.

4.3. Яклар әлеге Килешү шартларын үтәмәү яисә гамәлдәге законнар нигезендә тиешенчә үтәмәүләре өчен җаваплы.

4.4. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр гамәлдә, әгәр алар язмача рәвештә башкарылган һәм вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланган булса.

4.5. Әлеге Килешүне үтәгәндә барлыкка килгән бәхәсләр Яр Чаллы шәһәр суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды тарафыннан аларның компетенцияләренә туры китереп карала.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып 2 нче номерлы җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе тора.

5.2. Әлеге Килешү бер үк төрле юридик көчкә ия, 1 нче Якта – 1, 2 нче Якта – 1 данә, күчемсез милеккә хокукларны һәм сату-алу килешүләрен теркәүне гамәлгә ашыручы органда 1 данә саклана торган өч данәдә төзелә.

## 6. Якларның реквизитлары

| | |
|---|---|
| 1 нче Як:<br>«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ<br>Адресы: 423805<br>Татарстан Республикасы,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Х.Туфан пр., 23 йорт<br>ИНН ___________________<br>БИК ___________________<br>ОГРН __________________ | 2 нче Як:<br>_____________________________________<br>ИНН:<br>_____________________________________<br>Адресы: ______________________________,<br>_____________________________________<br>Паспорт ___________ бирелгән<br>__________<br>_____________________________________<br>_____________________________________<br>подразделение коды __________________,<br>туган көне - ______________________<br>тел.: |

____________________________________________

Якларның имзалары:

1 нче Як:

Башкарма комитет Җитәкчесе

____________________.

________________________________________

______________________________

(имза) М.У.

2 нче Як:

______________________________________

____________________.

___________________________________

М.У.

Башкарма комитетның
2018 елның 14 августындагы
4574 нче карарына
2 нче кушымта

Дәүләт яки муниципаль мөлкәттәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси мөлкәттәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы урынбасары | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгы | 30-59-72 | uzioIP@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе җир ресурслары белән идарә итү бүлеге белгече | 30-55-54 | uzioIP@yandex.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова